**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЗАРЕЧЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Заречный пос. **КАРАР**

«17» ноябрь 2025 ел № 6

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Юган поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Юган поселогында Осиновая Роща урамы 14нче йорт янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2025 елның 29 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
3.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Нурлат муниципаль районы Зареченск авыл җирлегенең Юган бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, СВОда катнашучылардан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

- Юган торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан җыештыру).

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башлыгы Л.Г. Еливанова